**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**10 август, 2022 ел** **№ 187**

**Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының хокукый хәлен камилләштерү турында» 2015 елның 02 февралендәге 424 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 24 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 4 бүлекнең 4.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Палата рәисе үз вазыйфасына Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирүче затлар арасыннан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча район Советы тарафыннан билгеләнә һәм үз вәкаләтләрен азат ителгән нигездә гамәлгә ашыра. Палата рәисе вазыйфасын биләүгә кандидатның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү Татарстан Республикасы финанс органы катнашында гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән тикшерүне уздыруда Татарстан Республикасы финанс органының катнашу тәртибе Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http//vysokaya-gora/tatarstan/ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары,
муниципаль район Башлыгы урынбасары Ә.Ш. Шакиров